# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровка Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**11.11.2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 11 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровка Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Пробуждение авылында урам яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;
- Беларус -82,1 тракторын карап тоту (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);
- Пробуждение авылының Х.Туфан, Татарстан урамнары юл өлешләренә вак таш җәю.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнардан 93 кеше, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан катнашучылар саны 76 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен җыенда катнашкан 76 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Петровка Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровка Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карарны танырга:

- Пробуждение авылында урам яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;
- Беларус -82,1 тракторын карап тоту (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);

-Пробуждение авылының Х.Туфан, Татарстан урамнары юл өлешләренә вак таш җәю кабул ителгән.

3. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Петровка Завод авыл җирлеге Пробуждение авылы, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровка Завод авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Петровка Завод авыл җирлеге башлыгы А. Б. Хөснетдинов